| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЧУТЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЧҮТИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 декабрь 2022 ел Чүти ав. № 52

Чүти авыл җирлеге Советының 2017 елның 07 августындагы 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Чүти авыл җирлеге Советының 2017 елның 07 августындагы 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы хисап чорындагы гомуми кеременнән артса, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма)

капиталларындагы катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, ул башкарган цифрлы валюта, аның хатынының (иренең) һәм (яисә) балигъ булмаган балаларының белешмәләр тапшыру елыннан алдагы календарь ел дәвамында (алга таба - хисап чоры) һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр һәм бу алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында мәгълүматлар»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне рәсми сайтка урнаштыру Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре тарафыннан тәэмин ителә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Рәсми сайтта урнаштырылган, шул исәптән алдагы еллардагы белешмәләр. вазыйфаи зат үз вазыйфасын биләгән чорда юкка чыгарылырга тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http:/ chuteev-tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Чүти авыл җирлеге Башлыгы П.П.Тараканов